**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**НЫРЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

20.02.2016 ел № 2

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүматны җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башлыгы белән төзелгән 2016 елның 12 февралендәге Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү буенча эш барышында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 28 гыйнварындагы 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге регламентына таянып эш итәргә.

2. Район башкарма комитетына җирлек Советының, авыл җирлеге Башлыгының һәм җирлек башкарма комитетының муниципаль норматив-хокукый актларын, шулай ук регистрга кертелергә тиешле алар турында белешмәләрне җибәрү өчен җаваплы итеп җирлек башкарма комитеты секретарен билгеләргә

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырып, халыкка игълан итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кукмара муниципаль районы
Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев

ОГРН 1061675010935
ИНН 1623008426